КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 27 апрель г.Казань № 340

Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен һәм Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда федераль бюджеттан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен, шул исәптән тулы күләмдә финанслашу максатларында, аерым хезмәт шартлары һәм гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен, финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып торган Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен

раслау турында» 2020 ел, 2 апрель, 415 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибе;

Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибе.

2. Бу карарның гамәлдә булуы 2020 елның 30 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 27 апрель,340 нчы
карары белән расланды

Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү механизмын билгели.

2. Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итешүгә Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бүтән бюджетара трансфертлар акчасы (алга таба – кызыксындыру характерындагы түләүләр) исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Башка бюджетара трансферт акчалары Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән яңа коронавирус йогышлы авыруы расланган очрагы булганда тотыла.

Башка бюджетара трансферт акчалары яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемдәге затларга медицина ярдәме күрсәтелә торган, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына караган медицина оешмаларына җибәрелә.

3. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыруга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүче – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыруга башка бюджетара трансферт чараларын җибәрә.

5. Башка бюджетара трансферт чараларын тоту Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган шәхси исәп счеты аша гамәлгә ашырыла.

6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы финанслауның иң чик күләмнәрен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләме һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан финанслауның иң чик күләмнәрен җиткергәннән соң расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җиткерә.

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру максатларында:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасының дәүләт бюджет яисә автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турындагы килешүнең бертип формасын раслау хакында» 2016 ел, 22 декабрь, 17-148 нче боерыгы белән расланган форма буенча һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 30 декабрь, 1052 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибе нигезендә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына караган бюджет һәм автоном учреждениеләр булып торучы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмалары (алга таба – медицина оешмалары) белән Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешүләр төзи;

Татарстан Республикасы бюджетыннан медицина оешмаларына субсидияләр бүлеп бирә.

8. Медицина оешмалары ай саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 2 числосыннан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән формалар буенча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына субсидия акчаларыннан файдалану турында хисаплар тапшыра.

9. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы бирелгән субсидияләрне медицина оешмалары тарафыннан түбәндәге очракларда кире кайтаруны тәэмин итә:

субсидия чараларында ихтыяҗның булмавы (кимүе);

медицина оешмалары тарафыннан дөрес булмаган хисап бирү;

медицина оешмалары тарафыннан субсидия чараларын максатсыз куллану.

10. Әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән очракларда медицина оешмаларына бирелгән субсидияләр акчалары Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының тиешле таләбе алынганнан соң 15 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Медицина оешмалары тарафыннан субсидия акчаларын кире кайтару срокларын бозганда, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән срок тәмамланганнан соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр акчаларын законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

11. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Татарстан Республикасының кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итүгә кергән башка бюджетара трансферт акчаларының максатчан кулланылышын контрольдә тотуны тәэмин итә.

12. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең «Электрон бюджет» дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында башка бюджетара трансферт бирү турында килешүдә билгеләнгән форма һәм срокларда, финанс ягыннан тәэмин итү максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисап урнаштыра.

13. Башка бюджетара трансферт акчаларыннан максатчан файдаланмау Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка китерә.

14. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына кулланылмаган башка бюджетара трансферт калдыгы, Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән таләпләр нигезендә, федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 27 апрель,340 нчы
карары белән расланды

Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне (алга таба – кызыксындыру характерындагы түләүләр) бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Кызыксындыру характерындагы түләүләр билгеләнә:

а) ашыгыч медицина ярдәме табибларына, шул исәптән махсуслаштырылган күчмә бригадалар составында – Дәүләт статистикасы федераль хезмәте мәгълүматлары буенча 2019 елның 9 аенда Татарстан Республикасында хезмәт эшчәнлегеннән уртача айлык керемнең 80 проценты күләмендә;

б) ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүдә катнашучы урта медицина персоналына (ашыгыч медицина ярдәме фельдшерлары, шәфкать туташлары, шәфкать туташлары-анестезистлар) – Дәүләт статистикасы федераль хезмәте мәгълүматлары буенча 2019 елның 9 аенда Татарстан Республикасында хезмәт эшчәнлегеннән уртача айлык керемнең 40 проценты күләмендә;

в) ашыгыч медицина ярдәме чакыруларын кабул итү һәм аларны ашыгыч медицина ярдәменең күчмә бригадаларына тапшыру буенча фельдшерларга (шәфкать туташларына) – Дәүләт статистикасы федераль хезмәте мәгълүматлары буенча 2019 елның 9 аенда Татарстан Республикасында хезмәт эшчәнлегеннән уртача айлык керемнең 20 проценты күләмендә;

г) беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүче бүлекчәләрнең табибларына (шул исәптән йогышлы авырулар табибларына, гомуми практика табибларына (гаилә табибларына), табиб-педиатрларга, участок табиб-педиатрларына, табиб-терапевтларга, участок табиб-терапевтларына, табиб-пульмонологларга) – Дәүләт статистикасы федераль хезмәте мәгълүматлары буенча 2019 елның 9 аенда Татарстан Республикасында хезмәт эшчәнлегеннән уртача айлык керемнең 80 проценты күләмендә;

д) беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүдә катнашучы урта медицина персоналына, шул исәптән фельдшер-акушерлык пунктларының, фельдшерлык пунктларының, фельдшер сәламәтлек пунктларының урта медицина персоналына – Дәүләт статистикасы федераль хезмәте мәгълүматлары буенча 2019 елның 9 аенда

Татарстан Республикасында хезмәт эшчәнлегеннән уртача айлык керемнең 40 проценты күләмендә;

е) беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтү өчен шартлар тәэмин итүче кече медицина персоналына – Дәүләт статистикасы федераль хезмәте мәгълүматлары буенча 2019 елның 9 аенда Татарстан Республикасында хезмәт эшчәнлегеннән уртача айлык керемнең 20 проценты күләмендә;

ж) стационар шартларда махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүче табибларга (шул исәптән йогышлы авырулар табибларына, табиб-анестезиолог-реаниматологларга) – Дәүләт статистикасы федераль хезмәте мәгълүматлары буенча 2019 елның 9 аенда Татарстан Республикасында хезмәт эшчәнлегеннән уртача айлык керемнең 100 проценты күләмендә;

з) стационар шартларда махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүдә катнашучы урта медицина персоналына – Дәүләт статистикасы федераль хезмәте мәгълүматлары буенча 2019 елның 9 аенда Татарстан Республикасында хезмәт эшчәнлегеннән уртача айлык керемнең 50 проценты күләмендә;

и) стационар шартларда махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тәэмин итүче кече медицина персоналына – Дәүләт статистикасы федераль хезмәте мәгълүматлары буенча 2019 елның 9 аенда Татарстан Республикасында хезмәт эшчәнлегеннән уртача айлык керемнең 30 проценты күләмендә.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына караган бюджет һәм автоном учреждениеләр булып торучы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмалары (алга таба – медицина оешмалары) Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән килештерелгән локаль норматив акт белән билгеләнә:

а) анда эшләү фактта эшләнгән вакыт өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне билгеләү хокукын бирә торган медицина оешмалары бүлекчәләре исемлеге;

б) анда эшләү фактта эшләнгән вакыт өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне билгеләү хокукын бирә торган медицина оешмалары бүлекчәләренең медицина хезмәткәрләре вазыйфалары исемлеге;

в) билгән вазыйфасы нигезендә кызыксындыру характерындагы түләү күләме;

г) кызыксындыру характерындагы түләү билгеләнә торган срок.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча медицина оешмалары заявкалары нигезендә кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыру өчен медицина оешмаларына субсидияләр рәвешендә акчалар күчерә.

5. Медицина оешмалары кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга акчаларны максатчан файдалану өчен җаваплы.